ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ с. Верхний Услон ______________ КАРАР

Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Югары Ослан муниципаль районы хакимияте органнарының физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү максатларында һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына һәм төзекләндерү кагыйдәләренә таянып, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен игътибарга алып, Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2. «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 11 декабрендәге 1590 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигына әлеге карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын үтәүне тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм бастырды:
Сагдеева А.Д.

2 экз.